ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘЗӘКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ
СӘЙТӘК АВЫЛЫ ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

КАРАРЫ

2022 елның 17 декабреннән. №6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Сәйтәк авылы гражданнар җыены

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

**1.** «2023 елда Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авыл җирлегенең Сәйтәк авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, ә 1 һәм 2 төркем инвалидлар һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, балигъ булмаган күп балалаы гаиләләрдән, көндезге уку формасы студентларыннан, Россия Армиясенә хезмәткә чакырылган гражданнардан 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Әлеге алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдереп, түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

- су насосы сатып алу
- кыш көне юлларны кардан чистарту;
- янгын коелары һәм гидрантлар сатып алу һәм урнаштыру;
- агачларны кисү
- Сәйтәк авылында су белән тәэмин итү челтәрләре өчен задвижкалар сатып алу

3. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында "Бәзәкә авыл җирлеге" бүлегендә - www.mendeleevsk.tatar.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында - pravo.tatarstan.ru урнаштырырга

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы И.И. Кәшәфетдинов